ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
КАРАРЫНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40. факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 06 2020 ел № 16

2020 елга Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль законга, 2020 елның 29 гыйнварындагы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 61 санлы карарына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына таянып, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында *җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә* ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2020 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 5 санлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитеты
к а р а р  и т ә:

1. 2020 елның 15 июненнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6 124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм . 1 санлы кушымта нигезендә «2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә православие йоласы буенча җирләүгә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге»н һәм 2 санлы кушымта нигезендә «2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу

бистәсендә мөселман йоласы буенча җирләүгә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге»н гамәлгә кертергә

2. 2020 елның 31 гыйнварыннан «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 3 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Шәрипов

2020 елның "22" 06
16 санлы
Ютазы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
башкарма комитеты
карарына
1 кушымта

2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә православие йоласы буенча җирләүгә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм күмү өчен кирәк булган башка предметлар биреп тору һәм илтү | 2 530,46 |
| 3. Үлән кеше гәүдәсен (калдыкларын) зиратка кадәр алуып бару | 718,89 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

2020 елның "22" 06
16 санлы
Ютазы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
башкарма комитеты
карарына
2 кушымта

2020 елның 15 июненнән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсендә мөселман йоласы буенча җирләүгә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Күмү өчен кирәк булган предметларны биреп тору һәм илтү | 1950,15 |
| 3. Үлән кеше гәүдәсен (калдыкларын) зиратка кадәр алуып бару | 718,89 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 875,51 |
| 5. Гәүдәне кәфенгә төрү | 580,31 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |